**СОВЕТ АТАБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422635 Лаишевский район,
село Атабаево,ул.Молодежная , д.1
тел,факс: 8(84378)-4-87-41
Atab.La@tatar.ru

**АТАБАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

422635 Лаеш районы, Атабай авылы
ул.Яшьлэр урамы, 1нче йорт
тел, факс: 8(84378)-4-87-41
Atab.La@tatar.ru

**2023елның 24 октябре** **148 номер**

# КАРАР

**«Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2011 елның 21 декабрендәге 31 номерлы Атабай авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

"Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" Федераль законга һәм "Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү турында" 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Атабай авыл җирлеге Советы **карар чыгарды**:

1. «Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2011 елның 21 декабрендәге 31 номерлы Атабай авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуныүз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Атабай**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Л.Р.Хәлилова**

*Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы*
*Атабай авыл җирлеге Советының*
*2023 елның 24 октябрендәге 148 номерлы*
*карарына кушымта*

**«Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2011 елның 21 декабрендәге 31номерлы Атабай авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

**1) 12 статьяның 10 пунктында**
- "Интернет" челтәрендә" сүзләрен "рәсми сайтларда" сүзләренә алмаштырырга;

**2) 15 статьяның 1 абзацы**

- «һәм җирле үзидарә органнары» сүзләрен «җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга, «хезмәткәрләр,»сүзеннән соң «ведомство буйсынуындагы оешмалар хезмәткәрләре» сүзләренә алмаштырырга;

3) **1 пунктның 7 статьясында**

- «һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләрен өстәргә .